**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗәсе авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«10» апрель 2024 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗәсе авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Рус Мәнҗесе авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы катнашучыларының тол калган хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан кала, 2000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- урам яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: А.И.Борисов

Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов